# Даңлыклы берләшмә

Юбилей кичәсе




/ АЙЗИРӘ ИМАМОВА ФОТОСЫ

Айзирә **Имамова**

**Чаллының «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе оешуга 60 ел тулды. Ул 1963 елның көзендә яшь каләмчеләргә үз ишекләрен ача. Башта түгәрәк буларак «Коммунизм байрагы» газетасы редакторы, журналист Хәнәфи Маннапов инициативасы белән эшли башлый.**

Бәйрәм уңаеннан шәһәрнең үзәк китапханәсендә «Ләйсән – моңлы бишегебез» дип аталган юбилей кичәсе узды. Ләйсәнлеләрне котларга шәһәр мәдәният идарәсе башлыгы Румил Кәрәмиев килде. Ул бүген Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты исемен йөрткән биш әдипнең иҗат чишмәләре «Ләйсән»нән башланганын билгеләп үтте. Шулай ук мөхтәрәм кунаклардан Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе, ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары Факил Сафин, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Чаллының мактаулы гражданины Гөлзада Рзаева, Чаллы милли матбугат үзәге җитәкчесе, «Шәһри Чаллы»ның баш редакторы Резидә Юсупова чыгыш ясады.

– Әле «Ләйсән»не оештыруда катнашкан кешеләр арабызда. 70нче еллар Чаллыда иң кайнар чорлар иде. Дөресен әйтергә кирәк, ул вакытта Чаллыга әдәбиятның «каймагы» килмәде. Кайдадыр нәрсәдер эшләргә тырышып та барып чыгара алмаган, яңа җирләргә килеп, хыялларын тагын бер кат тормышка ашырырга теләүчеләр җыелды. Үз-үзләренә ышанганнары да, ышанычлары сүреләбарганнар да бергә тупланып, зур әдәби мәйдан тергезделәр. Тора-бара Чаллы кайнап торган әдәбият дөньясына әйләнде» – дип сөйләде Факил Сафин.

Чаллының танылган шәхесе Гөлзада Рзаева да «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә йөргән булган. Мәктәптә укыганда ул берләшмәгә үзенең кульъязмаларын да алып килгән. «Нәрсә генә кулдан килми, тик шигырь яза алмадым. Ярый әле язмаганмын, аның каравы сезне рәхәтләнеп укыйм». – диде ул.

Бүген «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсен Роза Хәмидуллина җитәкли. Чаллының милли матбугат үзәге җитәкчесе Резидә Юсупова берләшмәнең әле дә гөрләп эшләвендә Роза ханымның өлеше зур булуын ассызыклады. «Быел газетабызда «Яшь каланың чал тарихы» дип аталган проект башлаган идек. Анда «Ләйсән» берләшмәсе турында да тарихи язма урын алды. Теләгән һәркем аны газетабыз сайтына кереп укый ала. Моны бездән юбилеегызга бер бүләк итеп кабул итсәгез иде», – диде Резидә Юсупова.

60 еллыклары уңаеннан «Ләйсән»леләр юбилей медале әзерләгән. Тантаналы төстә медаль-ләрне язучы-шагыйрьләргә һәм җырчыларга тапшырдылар. «Ләйсән»леләргә Татарстан Язучылар берлегенең, берлекнең *Чаллы* бүлегенең, *Чаллы* мэрының, башкарма комитет җитәкчесенең, мәдәният идарәсе башлыгының рәхмәт хатлары тапшырылды.